ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423740, Актаныш авылы, Лесная ур., 2 йорт

СОВЕТ АКТАНЫШБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423740, село Актаныш, ул. Лесная, дом 2

**РЕШЕНИЕ**
**04 март 2021 ел**

**КАРАР**
**№ 5**

**Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге Советының 07.09.2017ел, №22 «Актанышбаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив-хокукый актларны «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан, Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге Советының 07.09.2017ел, №22 «Актанышбаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11.2. бүлек, Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 12 нче абзац белән тулыландырырга:

«12) җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Актанышбаш җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Актанышбаш авыл җирлеге Советы Рәисе Х.М.Хакимов